**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ XXVII УТЫРЫШЫ**

КАРАР

18 октябрь 2022 ел №43

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баек авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баек авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 29 августындагы 41 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советының 2022 елның 29 августындагы 41 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8 статья. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегенең даими һәм вакытлы комиссияләре эшендә депутатның катнашуы»;

1.2. 9 статьяның 3 өлешен киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге йөкләмәне үтәү нәтиҗәләре турында депутат Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баек авыл җирлеге Советына яисә аның комиссиясенә хәбәр итә.»;

1.3. 10 статьяның 3 өлешендәге икенче җөмләне төшереп калдырырга;

1.4. 3 статьяның 1 пунктындагы 13 пунктчасын төшереп калдырырга;

1.5. 17 статьяның 1 өлешендәге 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында гамәлдәге законнар нигезендә белешмәләр тапшырырга.»

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Баек авыл җирлеге башлыгы: М.Ф.Фахерлегаянов